**«РАСЛЫЙМ»**
**Татарстан Республикасы**
**Мәгариф һәм фән**
**министры**
**___________ И.Г. Һадиуллин**
**«___» _________ 2022 нче ел**

# Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә укучылар өчен 2023 нче елда туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру материалларының күрсәтмә варианты

# Демонстрационный вариант контрольных измерительных материалов для проведения в 2023 году государственной итоговой аттестации (ГИА) по родному (татарскому) языку для учащихся-татар школ с русским языком обучения

разработан федеральным государственным автономным образовательным учреждением высшего образования
«КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ»

подготовлен государственным бюджетным учреждением
«РЕСПУБЛИКАНСКИЙ ЦЕНТР МОНИТОРИНГА КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ»

утвержден МИНИСТЕРСТВОМ ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# Туган (татар) тел буенча төп дәүләт имтиханы

## Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә укучылар өчен 2023 нче елда туган (татар) телдән төп дәүләт имтиханын уздыру материалларының күрсәтмә вариантына аңлатмалар

2023 нче елның күрсәтмә варианты белән танышканда, шуны истә тотыгыз: күрсәтмә вариантта тәкъдим ителгән биремнәр 2023 нче елда төп дәүләт имтиханын уздыру материалларының вариантлары ярдәмендә тикшереләчәк эчтәлекнең барлык элементларын чагылдырмый. 2023 нче елгы төп дәүләт имтиханында тикшерелергә мөмкин булган эчтәлек элементларының тулы исемлеге рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар укучылары өчен төп дәүләт имтиханына әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторында тәкъдим ителгән.

Күрсәтмә вариант имтиханда катнашучыларга һәм киң җәмәгатьчелеккә булачак имтихан эшенең структурасы, биремнәр саны, аларның формасы, катлаулылык дәрәҗәсе турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Бу варианттагы киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән биремнәрне бәяләү критерийлары җавапның тулылыгы һәм дөрес язылышы таләпләре турында күзаллау тудыра.

Бу мәгълүматлар имтихан тапшыручыларда 2023 нче елны туган (татар) тел буенча имтихан тапшырырга әзерлек осталыгын булдырачак.

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының**
**татар төркемнәрендә укучылар өчен 2023 нче елда**
**туган (татар) телдән**
**дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру**
**материалларының күрсәтмә варианты**

## Эшне башкару өчен күрсәтмә

Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларның татар төркемнәрендә белем алып, 9 нчы сыйныфны тәмамлаучы укучыларга туган (татар) телдән дәүләт йомгаклау аттестациясе өчен 3 сәгать 55 минут (235 минут) вакыт бирелә.

Имтихан эше үз эченә 8 биремне алган ике бүлектән гыйбарәт.

**Беренче бүлек** 7 биремнән (1-7) тора. Беренче бүлектәге биремнәр сүзләр, җөмләләр, текстны анализлауны таләп итә. Әлеге биремнәрнең җаваплары сүз (сүзтезмә) яки цифрлар белән җаваплар бланкына языла. Соңыннан 1 нче номерлы җавап бланкына күчерелә.

**Икенче бүлектәге** бирем 1 нче бүлек биремнәрен эшләгәндәге текст буенча башкарыла. Эшли башлаганчы, **тәкъдим ителгән биремнәрнең (8.1 һәм 8.2) БЕРСЕН ГЕНӘ сайларга** һәм үз фикереңне дәлилләп, эзлекле рәвештә киңәйтелгән җавап бирергә кирәк. Әлеге бирем 2 нче номерлы җавап бланкында эшләнә.

Бланкларны тутырганда, кара гель яки капилляр ручка кулланырга рөхсәт ителә.

Имтиханда орфографик сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт ителә.

Биремнәрне караламада эшләргә була, әмма андагы һәм тикшерү материалларындагы язулар билге куйганда исәпкә алынмый.

Үтәлгән биремнәр өчен куелган баллар бергә кушыла. Мөмкин кадәр күбрәк биремгә дөрес җавап биреп, югарырак балл җыярга тырышыгыз.

Эшләп бетергәч, 1 нче һәм 2 нче җавап бланкындагы һәр җавапның дөрес номер янында язылуын тагын бер тапкыр тикшерегез.

**Сезгә уңышлар телибез!**

## I бүлек

***1-7 нче биремнәрнең җавапларын сүз (берничә сүз) яки цифрлар белән языгыз. Һәр хәреф яки цифр бланктагы үрнәктәгечә аерым шакмакка язылырга тиеш. Сүзләр яки цифрлар буш шакмак калдырмыйча, өтерсез һәм башка тамгаларсыз языла.***

**1** *Синтаксик анализ.*
Текстны укыгыз.

(1) Күрешү, исәнләшүнең үз тәртибе бар. (2) Һәркем моны бик яхшы үзләштерергә тиеш. (3) Мәсәлән, сез урамда очрашканда, якыннарыгыз, дусишләрегез белән генә түгел, ә бер йортта һәм янәшә өйдә торучы күршеләрегез белән дә исәнләшергә тиешсез. (4) Гадәт буенча ирләр – хатын-кызлар белән, яшьләр – олылар белән, ә яшь хатын-кызлар олы яшьтәге ирләр белән беренче исәнләшәләр. (5) «Олыны хөрмәтли бел, кечене санлый бел», – дип, юкка гына әйтмиләр бит.

**Баш кисәкләр** дөрес билгеләнгән җавап вариантларының номерларын языгыз.

1) тәртибе бар (1 нче җөмлә)
2) моны тиеш (2 нче җөмлә)
3) сез исәнләшергә тиешсез (3 нче җөмлә)
4) ирләр, яшьләр, хатын-кызлар исәнләшәләр (4 җөмлә)
5) олыны бел (5 нче җөмлә)

Җавап: ____________________________.

**2** *Пунктуацион анализ.*
**Тыныш билгеләрен куегыз.** Өтер куелырга тиеш урыннарның цифрларын языгыз.

*Урманнарга (1) болын-тугайларга (2) күпме ямь (3) никадәр гүзәллек өстәлә!*

Җавап: ____________________________.

**3** *Синтаксик анализ.*
**Иялек килеше** кушымчасы ярдәмендә бәйләнгән сүзтезмәне табып языгыз.

*Тормышта һәр һөнәрнең алыштыргысыз урыны бар.*

Җавап: ____________________________.

| 4 |
|---|

***Орфографик анализ.***
Язылышы дөрес аңлатылмаган сүзләрнең номерларын языгыз.

1) **КУЛЪЯУЛЫК** – ъ билгесе я хәрефе алдыннан килгәндә, аеру билгесе буларак кулланыла һәм шуңа күрә калын иҗектән соң ъ билгесе языла.

2) **БАЛАЛАР** – калын әйтелешле сүз, шуңа күрә калын кушымча ялгана.

3) **ФЕВРАЛЬНЕҢ** – рус теленнән кергән сүзләр нечкә әйтелә, шуңа күрә нечкә кушымча ялгана.

4) **АТА-АНА** – парлы сүз, шуңа күрә сызыкча аша языла.

5) **ЯШЬЛЕК** – ь билгесе аеру билгесе буларак кулланыла һәм шуңа күрә нечкә иҗектән соң ь билгесе языла.

Җавап: ___________________________.

***Текстны укыгыз һәм 5-7 нче биремнәрне үтәгез.***

(1) Хәким күршеләрен бик ярата. (2) Яратуның төп сәбәбе – алма бакчасы. (3) Хәкимне бу тылсымлы бакча гел үзенә тартып тора.

(4) Бүген дә Алмаз бабайларның кояш нурында янып-пешеп утыра торган алмаларына күзе төште. (5) Аның шунда ук өзелеп алма ашыйсы килеп китте. (6) Авызына сулар килде. (7) Ул шып туктады да тирә-ягына карады. (8) Уе – беркем дә күрмәгәндә, бер-ике алма өзеп алу.

(9) Ул-бу күренмәгәч, тиз генә койманың җепсәсенә басып, кул астына туры килгән бер алманы өзеп, кесәсенә салды. (10) Аннары җиргә сикереп төште дә берни дә булмагандай атлап китте. (11) Бераз баргач, кесәсеннән алмасын алып, тешләре белән кетердәтеп тешләде һәм тәмләп чәйни башлады. (12) Тик алма, соң өлгерә торганы туры килгәнгә, ачы иде. (13) Малай аны бер-ике генә капты да җиргә ыргытты.

(14) Хәким аягындагы сандалиенең борыны белән җирне бераз тырнап торды да янә берәр алма өзәргә уйлады: тәмлерәге туры килмәсме? (15) Тиз генә коймага үрелеп меним дигән иде:

– Хәким улым, синме анда? – дигән тавышка сискәнеп китте.

(16) Бер мәлгә, кулын коймага сузган килеш, баскан җирендә катып калды, аннан соң качып китәргә теләп талпынып куйды. (17) Тик китә алмады, бар көчен җыеп:

– Алмаз бабай, бу мин, – диде.

(18) – Кер әле бире, кер, – диде бабай таләпчәнрәк тавыш белән.

(19) Хәким, икеләнеп-куркып, бер җирдә бераз таптанып торды да бакча капкасына таба юнәлде һәм:

– Хәзер, бабай, – дип, капканы ачып, бакча түренә узды.

(20) Алмаз бабай җиргә коелган алмаларны җыеп йөри. (21) Хәкимгә сынаулы күз карашы ташлап:

– Кил әле, улым, кил, – диде ул, кабатлап.

(23) – Яле, Хәким улым, карт кешегә бераз ярдәм ит, савабы үзеңә булыр.

(24) Алмаз бабай, кулындагы эре-эре алмаларны кәрзингә салып, көттереп кенә сүзен дәвам итте:

– Яхшылык җирдә ятмый ул, улым. (25) Кеше сиңа бер яхшылык эшләсә, син аңа меңне эшлә...

(26) Хәким дә, кулындагы алмаларын кәрзингә салгач, бабайга туры карамаска тырышып:

– Минем әни дә шулай ди, – дип куйды.

(27) – Шул шул... (28) Әнә күрәсеңме безнең калай түбәне?

(29) – Әйе, бабай. (30) Бик шәп эшләнгән.

(30) – Беләсеңме, кем эшләде аларны?

(31) Хәким, белмим дигәндәй, җилкәсен сикертеп куйды.

(32) – Әтиеңнең эше, улым. (33) Таза-сау, исән булса, әллә ниләр эшләп бетерер иде. (34) Алтын куллы булды шул әтиең.

(35) Шулай диюгә, Алмаз бабай хуш исле алмаларны кәрзине белән Хәкимгә тоттырды.

(36) – Монысы сезгә булыр, улым. (37) Әниең белән икәүләп, алма турап, чәй эчәрсез, алма бәлеше пешерерсез...

*(Н.Каштановтан*)*

****Нәкыйп Каштанов** (1942) – татар балалар язучысы, шагыйрь, табиб.*

**5** ***Текстның эчтәлеген анализлау.***

Текстның эчтәлегенә туры килә торган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Алмаз бабай – Хәкимнең күршесе.
2) Хәкимнәрнең дә бик бай алма бакчасы бар.
3) Алмаз бабай Хәкимне бакчага чакыра.
4) Алмаз бабайларның түбәсен Хәкимнең әтисе эшләгән.
5) Хәким Алмаз бабайга бер капчык алма җыеп бирә.

Җавап: ___________________________.

**6** ***Сәнгатьлелек чараларын анализлау.***

Фразеологик әйтелмә кулланылган җөмләләрнең номерларын языгыз.

1) Бүген дә Алмаз бабайларның кояш нурында янып-пешеп утыра торган алмаларына күзе төште.

2) Тик алма, соң өлгерә торганы туры килгәнгә, ачы иде.

3) Алмаз бабай җиргә коелган алмаларны җыеп йөри.

4) Авызына сулар килде.

5) Әниең белән икәүләп, алма турап, чәй эчәрсез, алма бәлеше пешерерсез...

Җавап: ___________________________.

**7** ***Лексик анализ.***
Тексттан «беркадәр» сүзенә синоним булган сүзне табып языгыз.

Җавап: ___________________________.

***Барлык җавапларны, эшне башкару буенча күрсәтмәдә әйтелгәнчә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга онытмагыз. Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

## II бүлек

**8.1** **«Кеше сиңа бер яхшылык эшләсә, син аңа меңне эшлә».** Текст ахырында китерелгән бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатып, сочинение языгыз.

Укылган тексттан фикерләрегезне раслый торган **ике** дәлил китерегез.

Мисаллар биргәндә, кирәкле җөмләләрне языгыз яисә аларның номерларын күрсәтегез.

Сочинениенең күләме 100 сүздән ким булмаска тиеш.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

**8.2** **ЯХШЫЛЫК** сүзен ничек аңлыйсыз? Үзегез формалаштырган билгеләмәне дәлилләгез. Үзегез язган билгеләмәне тезис итеп алып, **«Нәрсә ул яхшылык?»** дигән темага сочинение языгыз. Тезисыгызны раслый торган **ике** дәлил китерегез: дәлилнең **берсен** укылган тексттан алыгыз, **икенчесен** тормыш тәҗрибәгездән чыгып формалаштырыгыз.

Әгәр сочинение сөйләп чыгу яки чыганак текстны аңлатуларсыз тулысынча күчереп язу формасында гына булса, мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Сочинениенең күләме 100 сүздән ким булмаска тиеш.

Сочинениене пөхтә һәм аңлаешлы итеп языгыз.

***Һәр җавапның тиешле бирем номеры язылган юлда булуын тикшерегез.***

## Татар теле буенча имтихан эшен бәяләү системасы

### I бүлек

1-7 нче биремнәрдә һәр дөрес җавап 1 балл белән бәяләнә. Биремнәрнең җавапларын язганда, символлар тәртибе әһәмиятле түгел.

*1 нче таблица*

| Биремнең номеры | Бирем өчен алырга мөмкин булган максималь балл | Дөрес җавап |
|---|---|---|
| 1 | 3 | 134 |
| 2 | 2 | 13 |
| 3 | 1 | һөнәрнеңурыны |
| 4 | 2 | 35 |
| 5 | 3 | 134 |
| 6 | 2 | 14 |
| 7 | 1 | бераз |

I бүлек өчен алырга мөмкин булган максималь балл – **14 балл.**

### II бүлек
### 8 нче биремне бәяләү критерийлары
### 8.1 нче биремнең җавабы түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә

*2 нче таблица*

| № | Текст эчтәлегеН анализлауга бәйле темага язылган сочинениене (8.1) бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| **С1К1** | **Тексттан алынган кисәкнең мәгънәсен аңлау** | |
| | Укучы тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген дөрес аңлаткан. Аңлатмада хаталар юк. | 2 |
| | Укучы тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген гомумән дөрес аңлаткан,<br>**ләкин** аңлатмада 1 хата бар. | 1 |
| | Укучы тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген дөрес аңлатмаган,<br>**яки** укучы, тексттан алынган кисәкнең эчтәлеген аңлатканда, 2 яки күбрәк хата ясаган,<br>**яки** тексттан алынган кисәк эчтәлегенең аңлатмасы язма эштә юк. | 0 |

| | | |
|---|---|---|
| **С1К2** | **Дәлил-мисалларның булуы** | |
| | Укучы <u>тексттан</u> әлеге кисәкнең эчтәлегенә туры килә торган 2 дәлил-мисал китергән. | 3 |
| | Укучы <u>тексттан</u> әлеге кисәкнең эчтәлегенә туры килә торган 1 дәлил-мисал китергән. | 2 |
| | Укучы башка <u>тексттан</u> дәлил-мисал (-лар) китергән. | 1 |
| | Укучы әлеге кисәкнең эчтәлеген аңлата торган дәлил-мисал китермәгән,<br>**яки** укучы биремдәге цитатаны я аның бер өлешен дәлил-мисал итеп китергән. | 0 |
| **С1К3** | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле булуы, язу эзлеклелеге** | |
| | Укучының эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле булуы һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Укучының эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле булуы һәм эзлеклелек белән характерлана,<br>**ләкин** 1 логик хата бар,<br>**һәм/яки** абзацларга бүленештә 1 урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин** логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки** абзацларга бүленештә 2 урында хата бар. | 0 |
| **С1К4** | **Эшнең композицион бөтенлеге** | |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, текст төзүдә хаталар юк. | 2 |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән,<br>**ләкин** текст төзүдә 1 хата бар. | 1 |
| | Текст төзүдә 2 яки күбрәк хата бар. | 0 |
| **С1К1-С1К4 критерийлары буенча сочинение өчен иң югары балл** | | **9** |

**Игътибар!**

Чыганак текст күчереп кенә язылган яки текстның эчтәлеге генә чагылыш тапкан сочинение барлык критерийлар буенча (С1К1-С1К4) **0 балл** белән бәяләнә.

Башка текст нигезендә язылган сочинение С1К1-С1К4 критерийлары буенча **0 балл** белән бәяләнә.

Язма эшнең грамоталылыгы һәм аның фактик төгәллеге аерым бәяләнә (4 нче таблицаны кара).

**8.2 нче биремнең җавабы түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә**

*3 нче таблица*

| № | Текст эчтәлегенанализлауга бәйле темага язылган сочинениене (8.2) бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| С2К1 | **Төшенчәнең мәгънәсен аңлату** | |
| | Укучы (сочинениенең теләсә кайсы өлешендә теге яки бу формада) төшенчәгә билгеләмә биргән һәм аңлаткан. | 2 |
| | Укучы (сочинениенең теләсә кайсы өлешендә теге яки бу формада) төшенчәгә билгеләмә биргән,<br>**ләкин** аңлатмаган. | 1 |
| | Укучы төшенчәгә дөрес билгеләмә бирмәгән<br>**яки** укучының эшендә төшенчә аңлатылмаган. | 0 |
| С2К2 | **Дәлил-мисалларның булуы** | |
| | Укучы 2 дәлил-мисал китергән: берсе – тексттан, икенчесе тормыш тәҗрибәсеннән алынган<br>**яки** укучы укылган тексттан 2 дәлил-мисал китергән. | 3 |
| | Укучы укылган тексттан 1 дәлил-мисал китергән. | 2 |
| | Укучы тормыш тәҗрибәсеннән дәлил-мисал (-лар) китергән. | 1 |
| | Укучы дәлил-мисал китермәгән. | 0 |
| С2К3 | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле булуы, язу эзлеклелеге** | |
| | Укучының эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле булуы һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Укучының эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле булуы һәм эзлеклелек белән характерлана,<br>**ләкин** 1 логик хата бар,<br>**һәм/яки** абзацларга бүленештә 1 урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин** логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки** абзацларга бүленештә 2 урында хата бар. | 0 |
| С2К4 | **Эшнең композицион бөтенлеге** | |
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, текст төзүдә хаталар юк. | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| | Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, **ләкин** текст төзүдә 1 хата бар. | 1 |
| | Текст төзүдә 2 яки күбрәк хата бар. | 0 |
| **С2К1-С2К4 критерийлары буенча сочинение өчен иң югары балл** | | **9** |

**Игътибар!**

Чыганак текст күчереп кенә язылган яки текстның эчтәлеге генә чагылыш тапкан сочинение барлык критерийлар буенча (С2К1-С2К4) **0 балл** белән бәяләнә.

Башка сүз (гыйбарә) нигезендә язылган сочинение С2К1-С2К4 критерийлары буенча **0 балл** белән бәяләнә.

Язма эшнең грамоталылыгы һәм аның фактик төгәллеге аерым бәяләнә (4 нче таблицаны кара).

*4 нче таблица*

| № | Укучы сөйләменең грамоталылыгын һәм фактик төгәллеген бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| **ГК1** | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк **яки** хатасы 1 дән артык түгел | 2 |
| | 2-3 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| **ГК2** | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк **яки** хатасы 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3-4 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **ГК3** | **Грамматик нормаларның үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк **яки** 1 хатасы бар | 2 |
| | 2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 3 тән артык | 0 |
| **ГК4** | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләм хаталары юк **яки** хатасы 2 дән артык түгел | 2 |
| | 3–4 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| **ФК1** | **Язма сөйләмнең фактик төгәллеге** | |
| | Материалны язмада бирүдә, шулай ук аңлауда һәм терминнар кулланылышында фактик хаталар юк | 2 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 1 хата бар | 1 |
| | Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 2 хата бар | 0 |
| **ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча сочинение өчен иң югары балл** | | **10** |

Грамоталылыкны бәяләгәндә (ГК1–ГК4), **сочинениенең күләмен** истә тотарга кирәк.

4 нче таблицада бирелгән нормативлар сочинениедә 100 һәм күбрәк сүз булган очракта тәкъдим ителә.

Әгәр сочинениедә 50-99 сүз булса, ГК1–ГК4 критерийлары буенча 1 дән артык балл куелмый:

ГК1 – орфографик хаталар булмаса, 1 балл куела.

ГК2 – пунктуацион хаталар булмаса, 1 балл куела.

ГК3 – грамматик хаталар булмаса, 1 балл куела.

ГК4 – сөйләм хаталары булмаса, 1 балл куела.

ФК1 – фактик хаталар булмаса, 1 балл куела.

Әгәр сочинениенең күләме 50 сүз һәм 50 сүздән дә кимрәк булса, ГК1–ГК4, ФК1 критерийлары буенча мондый эш 0 балл белән бәяләнә.

Имтиханны тулаем башкару барышында җыярга мөмкин булган максималь балл – **33.**

**Имтихан эше өчен түбәндәге билгеләр куела:**

0-14 балл – «2» ле билгесе;

15-22 балл – «3» ле билгесе;

23-28 балл – «4» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучының ГК1-ГК4 критерийлары буенча баллары 4 тән кимрәк булмаска тиеш.

29-33 балл – «5» ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучының ГК1-ГК4 критерийлары буенча баллары 6 дан кимрәк булмаска тиеш.